Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Азалаковского сельского
поселения Сармановского
муниципального района.
423371 с. Азалаково ул Зеленая дом 4
Телефон ( 85559) 4 – 80 – 36

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл жирлеге башкарма комитеты.

423371 Азалак авылы Яшеллек урамы
4 йорт.

# РАСПОРЯЖЕНИЕ № 8

с.Азалаково 24.03.202015 ел

## Авыл җирлегенең торак пунктларын санитар чистарту, яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча икеайлык үткәрү турында.

Әйләнә-тирәлекне саклау, экологик культура формалаштыру һәм үстерү мәсьәләләренә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатларында. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 24 февралендәге 388-р номерлы күрсәтмәсен, Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 мартындагы 60 номерлы боерыгын үтәү һәм торак пунктларны халыкның санитар-эпидемиологик һәм экологик иминлегенә җавап бирүче халәткә китерү максатларында:

1. 2015 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр торак пунктларны санитар чистарту, яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча санитар - экологик икеайлык игълан итәргә.
2. Җаваплы башкаручыларга, предприятие, учреждение, оешма житәкчеләренә икеайлыкны әзерләүдә һәм үткәрүдә актив катнашырга кирә.
3. Авыл жирлеге территориясендә санитар чистарту, яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча чаралар планын расларга. (кушымта No. 1)
4. Барлык оешма, предприятие җитәкчеләренә үз территорияләре чикләрендә икеайлык чорына санитар чистарту, яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча чаралар планын эшләргә, атна саен (һәр пәнҗешәмбе) Азалак авыл җирлеге башкарма комитетына башкарылган эшләр турында оператив мәгълүмат бирергә.
5. Җирлекнең һәр урамына җаваплы учреждениеләр билгеләргә.
6. Әлеге күрсәтмәне Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең рәсми сайтында халыкка җиткерергә.
7. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Т.М.Гараев

1 нче кушымта.
җитәкче боерыгына Азалак авыл җирлеге
башкарма комитеты
2015 елның 24 марты, № 8

# Эшләр планы
## Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге территориясен санитар чистарту, яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча 01.04.2015 - 31.05.2015 ел

| № | Чараларның исеме | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|
| 1 | Авыл җирлеге гражданнары җыелышларын уздыру | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2 | Икеайлык үткәрү буенча чаралар планын әзерләү һәм раслау | Башкарма комитет секретаре |
| 3 | Җирлектә аңлату эшләрен үткәрү, белешмәләр тарату | СП башкарма комитеты |
| 4 | Торак пунктларны яшелләндерү, агачлар һәм куаклар утырту | СП башкарма комитеты, учреждение җитәкчеләре |
| 5 | Терлекчелек фермалары территориясен, үләт базларын, минераль ашламалар складын һәм башка җитештерү объектларын чистартуны оештырырга | «Нөркәй» АФ, бүлекчә җитәкчесе; фермер хуҗалыклары: Ашрафуллин Р.К., Закиров И.С., Гыйбадуллин Р. Р.. |
| 6 | Рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләрне бетерү. | «Нөркәй» АФ, бүлекчә җитәкчесе; авыл җирлеге башкарма комитеты, бюджет оешмалары |
| 7 | Торак пунктларны агачлар, куаклар утырту белән күпләп яшелләндерү үткәрергә | Авыл җирлеге башкарма комитеты, бюджет оешмалары хезмәткәрләре |
| 8 | Чишмә территорияләрен чистарту һәм төзекләндерү | Авыл җирлеге башкарма комитеты, бюджет оешмалары хезмәткәрләре |
| 9 | Урамнарда һәм юллар янындагы баганалар агартылды | Авыл җирлеге башкарма комитеты, бюджет оешмалары хезмәткәрләре |
| 10 | Һәйкәлләр тирәсендәге территорияне чистарту һәм төзекләндерү | Авыл җирлеге башкарма комитеты, бюджет оешмалары хезмәткәрләре |
| 11 | Оешмалар территориясендә чәчәк түтәлләре урнаштыру | СП территориясендәге оешма җитәкчеләре |
| 12 | Җирле үзидарә территориясендә аншлагларны тәртипкә китерү | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 13 | Зиратларны ремонтлау һәм чистарту буенча өмә оештырырга | Имам-хатиб, СП Башкарма комитеты. |
| 14 | Юл буе полосаларын чүп-чардан чистарту, тиешле халәткә китерү | СП Башкарма комитеты территориясендәге оешма җитәкчеләре |